
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!


ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАРТ * 2025 * КАЗАН

3





Александр ШУЛЬПИНОВ

АЧЫК ХАТ

– Нәни диеп аталса да,
Гаилә ул – бер Дәүләт.
Һәм бу Дәүләтнең башлыгы,
Билгеледер, ул – ир-зат.

Ир – баш, хатын – муен, әйе,
Баш муенны хөрмәтли.
Хөрмәт әз булган Дәүләттә
Тормыш булмый (э)рәтле.

Хатыны өчен җаваплы
Аллаһ каршында ире.
"Бу җаваптан хатын азат",
Коръән дә шулай диде.

Хатыннар, учак тергезеп,
Саклый өйнең җылысын.
Дога кыла намаз саен:
– Иремнең юлы уңсын...

Ир башы, ат һәм эт башы –
Ишегалды – урамда.
Хатын, бала-чага, пескәй –
Ак өйнең түр башында.

Наз, җылы сүз, назлы караш
Тансык әтиләргә дә.
Тартына, нигәдер телләр,
"Яратам!" сүзен әйтергә.

Белеп әйткән борынгылар:
"Кыз гаебе – Анага".
Тәрбияне кыз балалар,
Күб(е)рәк Анадан ала.

Гореф-гадәт сакланмаса,
Гаилә җирен чүп баса.
Тирә-юньгә күз ташласак,
Килеп җиттек ләбаса...

Ата – кызны, ана – улны
Белми торган бу чорга
Алмаштылар Ата-Әнкәне
Бик күпләре ваучерга.

Яшереп түгел, "Чаян"ым,
Язам сиңа Ачык хат.
Шөшле ятмыйдыр капчыкта,
Илдә бит – "матриархат".

"Йорт хуҗасы кем?" дигәндә,
Ир-зат әйтә: "Мин!" – диеп.
Шулчак хатыны карап куйса,
Төшә куырылып-көеп.

– Мин, мин, мин, – ди йорт хуҗасы, –
Эшлим... Хатын кушканча.
Бигүк кирәсе килмидер шул,
Һәр көн эссе мунчага.

Әллә миф, әллә чынлапмы
Булды микән "патриархат"?!
Җаваплап ошбу сорауга,
"Чаян" дус, яз әле бер хат.

Сәлам белән, Хәмид ВӘЛИДИ.



Николай ВОРОНЦОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле «Чаян»! Хыялым – читтән торып эшләү. Иртә таңнан торып эшкә чабасы түгел, эш көнеңне үзең планлаштырасың, өстеңдә нәчәлнигең тормый, эч пошырып коллегалар утырмый... Рәхәт!

Л. МАНСУРОВА

КАЗАН

Хатны без Шомбай агага күрсәттек.

– Ә минем күршем менә өеннән бик читтә урнашкан эшеннән зарлана, – диде аксакалыбыз. **– Көн саен барып җитәргә ике сәгать китә, ди.**

Дамир МОРТАЗИН

Елмаю

Тышта яз. Эреп бетмәгән карлар кояш нурларында җемелди, кошлар черкелди, аяк астындагы тайгак боздан арынып, җәяүлеләр шатлана. Табигать үзгәрешләр көтә, ә урам буйлап миңа каршы Рәсим килә. Күреп торам: йөзендә нур юк. Аның караңгы карашы мине шикләндерми. Аның белән инде берничә ел бергә бер коллективта эшләгән кеше мин, беләм гадәтен. Ул елмая белми, хәтта "Чаян" укыган чагында да.

Ләкин бу юлы язгы кәеф күтәренкелеге тәэсирендә һәм аның "Ничек хәлләр?" диюенә ияреп, күңеллерәк тормышка кайту өчен, үзебездә нинди яхшы яңалыклар барын сөйләргә тотындым.

– Хезмәт хакын бер меңгә күтәрделәр... Вахтага йөри торган автобусны ниһаять төзәттеләр... Ашханәдә тәмлерәк пешерә башладылар... – дидем.

Мин сөйлим, ә ул колак та салмый. Шунда мин моңа икенче төрлерәк итеп сүз кактым.

– Хәтерлисеңме, сату бүлегеннән Мангаловны?

– Теге, гел миңа бәйләнә торганмы?

– Шул инде. Аның хәзер хәлләре бик мөшкел.

Рәсимнең кашлары күтәрелеп куйды, җанланып китте.

– Вәли Вәлиевич – директорыбыз – планёркада аның кирәген шәп бирде, хәтта теге үз теләге белән эштән китәргә дә әзер иде...

– Чынлапмы? – дип шатланып сорады Рәсим.

– Әйе, үзем Мангаловтан ишеттем!

– Күптән куарга кирәк иде инде ул ялкауны, – диде иренеп кенә Рәсим.

– Аның ипотекасы һәм машинасы кредитка алынган!

– Кредит алганчы баш белән уйларга иде! – дип җиңел генә әйтеп куйды Рәсим.

– Болары әле пүчтәк. Аны хатыны ташлап киткән. Ул булдыксыз белән яши алмыйм, – диган.

– Шул кирәк аңа! – дип иркен сулап әйтте бу сүзләрен Рәсим.

Рәсимнең йөзе яктырып китте. Күзендә нур балкыды, ә караңгы йөзе гомерендә күрмәгән елмаю белән балкыды.


Валентин ДУБИНИН

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Җүләрләр өйләнә, акыллылар кияүгә чыга.

Әгәр хатының сине бәдбәхет дип атаган икән, димәк, син барысын да дөрес эшләгәнсең.

Әгәр егермедә өйләнмичә калгансың икән, аннан соң иртә булачак.

Әгәр бөтен нәрсәне дә салкын акыл белән эшләсәк, җүләрләрне кая куярбыз?

Әгәр дә син үзеңне бер көннән артык бәхетле итеп тоясың икән, димәк, синнән нидер яшерәләр.

(Акыллы башлар мәҗлесендә язып алынды.)



Сергей КОКАРЕВ

Юка бозда

Боз өстендә күлләвекләр, түбә кырыенда язгы тамчылар, җылы җил – быелның беренче ае шундый әйберләр белән гаҗәпләндерде. Ләкин табигатьнең бу уены бернигә дә карамый, бернәрсәдән курыкмыйча боз астыннан балык тотарга яратучыларны һич тә туктата алмый. Хәтта бозның гадәттән тыш юка булуы, уйламаганда салкын суда коенып чыгу куркынычы да аларга киртә түгел. Чөнки кармак салып утыруны боз астына китү мөмкинлегеннән артыграк күрмәгән кеше Идел йә Чулман балыгыннан пешкән шулпа ашый алмый. Шуңа күрә алар, дөньяларын онытып, бу хәвефле гамәлнең ахыры турында уйламыйча, елга-күлләргә омтылалар.

Күрше Удмуртиядә ике балыкчы бозлы суда чирканчык алудан чак кына котылып калганнар. Алар Әгерҗе районындагы Салагыш авылы янында Ык елгасының юка бозына кар машинасында чыгып, балыкчы бәхетен сынап карамакчы булганнар. Кирәк-яракларын бушата башлау белән, соңгы җылы көннәр – дә эри башлаган февраль бозы аяк асларында утыра башлаган. Куркудан акылларын җуйган егетләр, батып баручы "тимер ат"та кармакларын, мобильникларын һәм резин итекләрен онытып, боз ватылган урыннан табан ялтыратканнар... Ләкин боз астында балык тоту осталарының күңелсезлекләре моның белән генә тәмамланмаган. Берсенә, ярдәм эзләп, янәшәдәге авылга җәяүләп барырга туры килгән. Ә аның дусты, коткаручылар килгәнне көтеп, ярда биеп торган... Бу "балык тоту", дусларның хәтерендә, һичшиксез, озак сакланыр: чөнки ул аларга бик кыйммәткә төшкән. Ыкның салкын кара төбенә киткән кар машинасына коткаручылар тарафыннан юка боз өстенә чыккан өчен салынган штрафлар да өстәлгән бит.

Әйтергә кирәк: удмурт егетләренә бәхет елмайган дисәк тә була.

Боз астында балык тотарга тагын бер яратучыга табигать көчләренең бөтен "ләззәтен" тоярга туры килгән. Республикабыз башкаласында яшәүче ир-егет Казансуның декабрь бозы астына китә язган. Зәңгәрләнеп, суыктан ярдәм чакырыр хәле бетеп барган чакта аны МЧС коткаручылары судан сөйрәп чыгарган.

Иң гаҗәбе шул: боз астында йөзү очраклары бу балыкчыларның балык тоту теләген һич суыта алмый. Юка боз өстендә нервларын сынап карарга теләүчеләрнең саны һич кимеми. Быелның гыйнварында гына МЧС хезмәткәрләре ике дистәдән артык беркетмә язып, дистәләгән мең сумлык штраф салганнар. Тик бу штрафлар балыкчыларга елга маймычлары кебек вак кебек тоела, күрәсең. Алар елдан-ел, тормышларын куркыныч астына куеп, шома тәнле бәхетне койрыгыннан эләктерү хыялы белән боз өстенә омтылалар. Әмма үзләренең шул боз астына бөтенләйгә китү куркынычын аңлап бетермиләр бугай. Аннан кире юлның булмавы башларына да керми ахрысы...

Артём СУББОТКИН

"ЧАЯН"нан. Бу мәсьәлә шулкадәр нык кискенләшкән ки, кышын балык тоткан өчен штраф салырга да тәкъдим кузгатылган, чөнки бату куркынычы туган очракта, балыкчыларны коткару чаралары зур чыгым сорый, диләр. Әгәр дә мондый куркыныч туу фактын кисәтеп тә балыкчылар тыңламаса, коткару чаралары үтәү зыянын үзләре бишләтә түләп капларга тиеш булачак.

Игорь КИЙКО





Вячеслав ШИЛОВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Валентин ДУБИНИН



• • •

– Россиядәге иң авыр дип саналган эш билгеле. Беренче урында – иминиятләштерү, аннан соң персонал белән идарә итү һәм маркетинг.

– Ә шахтёрлар, корыч коючылар, пожарниклар?

– Аларның рух төшенкелегенә бирелергә вакытлары юк.

• • •

– Кадерлем, чәчләремне алсу төскә буярга телим.

– Нигә?

– Башымны ничек тә булса яңачарак итәргә телим.

– Китап укы...

• • •

Хайваннар дөньясындагы айтишниклар аналогы – пандалар. Алар бигүк мөстәкыйль түгелләр, бик кәмит кенә урындыклардан егылалар, әмма югары бәяләнәләр.

• • •

– Россиядәге халыкның өчтән бере, ясалма интеллекттан шөлләп, эшләреннән коры калудан курка.

– Юкка куркалар, чөнки бернинди ясалма интеллект 20 меңгә эшләргә риза булмаячак.

• • •

Ә менә "Слон и Моська" мәсәле – шәхси бренд тудыру турында. Гаять күп шәһәр этләренең берсе көндәшен дөрес сайлаган – иң зурын һәм бу очракта бердәнберен. Шуның нәтиҗәсендә тарихка кереп кала, ә филнең исеме ничек булганын берәү дә белми.

• • •

Юлны аркылы чыгу урынында машина җәяүлене бәрә. Руль артындагы машина йөртүче йөгереп чыга да, башын ия-ия, һәлакәткә очраган кешегә:

– Ярый әле сезгә мин туры килдем, мин – врач, – ди.

Тегесе егылган урыныннан торып:

– Юк, сез уңмадыгыз, мин – прокурор! – дип әйтә.

• • •

– Ханым, рөхсәт итегез, сез нәрсә белән кызыксынасыз?

– Психиатрия белән.

– Аңлатыгыз әле.

– Юк, үзем психланам.

• • •

Билгеләр. Хатын-кыз бер фикергә килә алмый икән – бәла көт. Ә инде фикергә килә алса – бәла чынлап булачак.

Абау!

ОТЧЁТ ӨЧЕН ШТРАФ

Тукай районы фермерлары, эшләрен гадиләштерергә тиешле цифрлаштыруның аларның үсешенә комачаулый, дип зарланалар. Хәзер барча таләп ителгән мәгълүматны интернет аша тапшырырга кирәк. Ләкин ул бөтен җирдә дә юк, булса да, еш кына начар эшли. Өстәвенә, бөтен фермерларның да отчёт төзү нечкәлекләрен белүче бухгалтерлары юк. Менә шулай, крәстиянгә авырлык һәм савылган сөт артымы түгел, ә инструкцияләрне бозмыйча гына вакытында цифрлы документларны тапшыру турында кайгыртырга туры килә. Ә соңарсаң, штраф салуларын көт тә тор.

"УКЫТМАУ ҮЗӘГЕ"


Казанда урнашкан «SkillPlace» укыту онлайн үзәге үзенең бөтен илдән җыелган 900 студентын читтән торып укуга ышанмаска өйрәткән. Башта компания хәзерге вакытта таләп ителгән белгечлекләр буенча курсларына актив реклама алып барган. Укучылар һәм акча җыйгач, уку үзәге студентлар белән эшне туктаткан, укытучылар юкка чыккан, ә хезмәткәрләре элемтәгә чыкмый башлаган. Акчаны кайтару турында компания сүз алып барырга теләми. Онлайн үзәгенең "эшчәнлеге" белән прокуратура шөгыльләнә башлаган.


СӘЕР ДУСЛЫК

Рәшәткә артына эләккән ике Казан егете озак ямансулап утырмаган. Алар үзләре белән утырган иптәшләре исеменә ялган паспорт ясаганнар һәм аның фатиры сатылу турында белдерү биргәннәр. Рольләрне гадел итеп бүлгәннәр – берсе "риелтор", икенчесе "фатир хуҗасы" ролен уйнаган. Аферистлар дусларының фатирын берни дә белмәгән сатып алучыга 2,4 миллион сумга сатканнар. Әмма ялган тиздән ачылган. Торак кире хуҗасына кайткан, ләкин дусларын югалткан.

КЕСӘДӘГЕ СРОК

Түбән Камада яшәүче бер бәндә хөкемдарларны бик нык гаҗәпләндергән. Ул үзенең наркотиклар белән бәйле җинаятен карау утырышына кесәсенә синтетик матдә салып килгән. Тикшерү вакытында тәргәкне тапканнар, һәм судка оперативникларны чакыртганнар. Гаепләнүченең күптәннән наркоман булуы ачыкланган, ә дозаны ышанып тапшырырлык кешесе булмаган. Гадәттән тыш ышанмаучанлыгы аркасында ул тагын бер статья буенча – тыелган матдәләр саклау һәм аны күчереп йөртү өчен хөкем ителәчәк.


Владимир СОЛДАТОВ



Сергей КОКАРЕВ


Игорь КИЙКО

Бәйрәмегез белән, гүзәл затларыбыз! "Чаян"нан сезгә бер кочак шигырь бәйләме – балкыгыз, нурланыгыз, яратыгыз, сөегез! Шатлык-бәхетләр яусын киләчәк тормышыгызда!

Ләбиб ЛЕРОН

МИН ЯРАТАМ СЕЗНЕ, ГҮЗӘЛЛӘР!

Кояш кебек сезнең йөзләрегез,
Якты, нурлы сезнең күзләрегез,
Балдай татлы сезнең сүзләрегез –
Мин яратам сезне, гүзәлләр!

Мин елмаям, әгәр елмайсагыз,
Мин моңаям, сез дә моңайсагыз,
Мин куанам, сез дә куансагыз –
Мин яратам сезне, гүзәлләр!

Һәр көнегез сезнең көләч булсын,
Күк йөзендә һәрчак кояш булсын,
Күңелләрдә сезнең гел яз булсын –
Мин яратам сезне, гүзәлләр!

ЗӨЛФӘТ

БЕЗНЕҢ БОЛЫННАР

Кызларны без дәштек болыннарга...
Болыннарда атлар уйнатып.
Шул болында кошлар
Җылысы бар –
Җылыйсылар
килә бер ятып...

Кыяр-кыймас атлап килде сылу.
Көттем аны болын түрендә.
Гөлләр исе бездән
Аңкып торды,
Балкып торды
дөнья күгендә.

Кыяр-кыймас атлап килгән кызлар!
Сез кыюдыр дөнья көткәндә...
Беләм, ефәкләргә
Төрмәс идем –
Бирмәс идем
ләкин бүтәнгә!

Утка кагылгандай була идем
Сыйпаганда аның толымын...
Сөйгәнемне әгәр алсам үбеп:
"Аб-бау!" диеп
тынды бу болын.

Сагышлымы сезнең яратулар?
Сөюләрдән бармы ярагыз?
Сезнең өчен яшим
Кимсенгән күк –
Мин сөйгән күк
сөеп карагыз!

Кызны болыннарга дәштек бит без!
Болыннарда атлар уйнаттык!
...Шул болыннарда кызлар
Җылысы бар –
Җылыйсылар
килә бер ятып...

Рашат НИЗАМИ

* * *

Син миңа күзләр бирдең:
чыктагы салават күперен,
таш өстендәге гөлләрне,
күлгә төшкән айны күрергә өйрәндем.
Син миңа тел бирдең:
дөньядагы иң көчле,
Җирдәге иң татлы,
иң назлы сүзләрне әйтергә өйрәндем.
Син миңа көч бирдең:
өстеңә чөелгән дулкынны,
юлыңа ишелгән ташларны
читкә алып ташларга өйрәндем.
...Син пышылдап нибарысы:
– Яратам, – дигән идең.

Георгий ИБУШЕВ

БУЛСА БУЛЫР ИКӘН

Ул, искиткеч матурлыгы белән,
Назлы гөлдәй җәйге бакчада,
Нурга тулып, балкып басып тора,
Ярсу яшьлек яме бар анда.

Йомшак кына искән талгын җилдә
Иңнәренә төшкән чәчләре
Тибрәп-тибрәп куя дулкынланып.
Аһ, язмыни? Хушбуй исләре...

Соклanудан, бөтен тәнем буйлап
Бер чемерәү уза йөгереп, –
Ходай биргән шушы могҗизаның
Күз алдында торганын күреп.

Күз карашын алып булмый аннан,
Йөрәк кагып куя ярсынып,
Кычкырасы килә: "Булса булыр икән
Җир йөзендә шундый матурлык".

Никифор ТУКМАЧЁВ

ГОМЕР АГЫШЫ

Өйләнешеп туйлар иттек,
Дус-туганнар килделәр.
Котладылар теләк теләп,
Бүләкләрен бирделәр.

Барсы да күңел ачтылар,
Җырлады, биеделәр.
Менә син дә башлы-күзле
Булдың инде, диделәр.

Ачы... ачы диештеләр
(Үбешегез янәсе).
Илле елдан аңлашылды
Шул сүзләрнең мәгънәсе.

Әче... әче дигәннәре
Ул хәмер түгел икән.
Шампан шәрабы да түгел,
Кәләшнең теле икән.

Башлы-күзле дигәннәрен
Хәзер генә шәйләдем.
Ул чагында башсыз-күзсез
Булганымны аңладым.

Үткән гомер елларыбыз
Хәмердән әче кебек.
Инде гомер үткәрәбез
Эт белән мәче кебек.

Барсына да төшендем күк,
Гомернең җәе үткәч.
Уңышны да, акылны да
Җыябыз шул көз җиткәч.

Хәмид ВӘЛИДИ

ШАГЫЙРЬ ХАТЫНЫНЫҢ СҮЗЛӘРЕ...

Шагыйрь белән гомер итү
Бик җиңел дип беләсезме?!
Аның белән бер Ай гына
Яшәтер идем сезне.


Иртәнге якта сабый ул,
Кичкә керсә, карт кеше.
Гел язып утырса, бер хәл,
Һәрнәрсәдә бар эше.

Вакчыллана, дип әйтмимен,
Шагыйрьҗан вакчыл булмый.
Бер сүз белән әйткән чакта
Аларга, һәй,
Аларга... "нидер" тулмый.

Берни юктан шатланыр, йә,
Моңланыр – сәер кеше.
Салган ашы суынып бетәр,
Хәтта өч кабат пешеп.

Житәрлек кәефсез чагы,
Кәефле чагы сирәк.
Шагыйрь белән көн итәргә
Бер пот сабырлык кирәк...

Ходай сабырлыклар бирсен
Шагыйрьгә чыкканнарга.
Тик, шулай да, шагыйрь алса,
Сеңелем, чыкмый калма.
...Истә тот анаң сүзен.



Ринат АБЗАЛОВ



Машина-тамаша

Юл хәбәрләре

• Татарстанның Конституция советы Казан хакимиятенә иҗтимагый объектлар – мәктәпләр, балалар бакчалары, медицина учреждениеләре янындагы парковкалар өчен түләүне бетерергә тәкъдим ясады. Ахыргы карар ТР Дәүләт Советы һәм парковка территорияләренең хуҗалары тарафыннан кабул ителергә тиеш. Соңгыларына карата һичнинди шик юк – алар бөтен Казанны түләүле зона итәргә әзер. Шуңа күрә бөтен өметне депутатларга баглыйсы кала.

• Россиялеләрдән әллә кайчан сатып алынган машиналар өчен өстәмә түләү таләп итәләр. Автомобильләрен түбән бәягә алган меңләгән хуҗаларга утиль салымы түләү турында хәбәр кәгазьләре килгән. Алар барысы да "көпчәк"ләрен ялган таможня документлары буенча шикле автосалоннарда һәм кулдан алганнар. Суд аша бу хәлнең очына чыгу мөмкин түгел – таможняның гамәлләрен барыбер дөрес дип таныячаклар, ә тикшерү эшләре барган арада, түләү суммасын икеләтә артып, пени җыелачак.

• Узган ел эчендә тугыз меңнән артык Чаллыда яшәүче газонда парковка ясаган өчен штрафка тартылган. Машиналарын өй янындагы яшел чирәмгә куючыларга салынган штрафның гомуми суммасы 26,5 миллион сум тәшкил иткән.

• Чабаксарда яшәүче берәү троллейбус паркыннан башы троллейбус ишегенә кысылган өчен 50 мең сум алган. Пассажирның салоннан чыгып җиткәнен көтеп тормыйча, бичараны чираттагы тукталышка кадәр сөйрәп барган йөртүчене суд гаепле дип таныган.

• 2ГИС сервисы Россиядәге миллионлы шәһәрләрнең 2024 елгы юл хәбәрләрендәге ике йөз меңнән артык комментариен анализлаган. Һәм шунда Казан йөртүчеләренең иң актив рәвештә "Слово пацана" сериалы, Киләчәк уеннары һәм БРИКС саммиты белән бәйле юл хәлләре турында фикер алышканнары ачыкланган.

• Кузбасста юл инспекторлары исерек машина йөртүчене туктатканнар. Ир кеше аклану өчен үзен император Николай II нең токымыннан дип ышандырырга маташкан. Әмма бу полицейскийларны әллә ни тәэсирләндермәгән. "Патша оныгын" правасыннан мәхрүм иткәннәр һәм штрафка тартканнар.

• Техаста яшәүче 101 яшьлек Томас Дэвис, үзенең "булдыра алуын" исбатлау өчен, күптән түгел правасын яңарткан. Икенче бөтендөнья сугышы ветераны әлегә кадәр пикапында төзелеш материаллары һәм супермаркеттан продуктлар ташый. Дэвис нәселләрендә иң өлкәне түгел икән, аның абыйсы моны 103 яшендә эшләгән.

• Формула-1 пилотларына кычкырып та, язма рәвештә дә сүгенергә, шулай ук кимсетүле ишарәләр ясау тыелган. Бу кагыйдәне беренче тапкыр бозган өчен "хулиган"нарга 40 000 евро штраф салына. Бу, әлбәттә, миллионлаган гонорарлар алучы өчен бик зур сумма түгел, ләкин икенче тапкыр элагүнең ярышлардан читләштерүгә китерүе мөмкин.




Вячеслав ШИЛОВ



Александр ШУЛЬПИНОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ


Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Александр БРЮХАНОВ

Тормыш юлы

– Тукранов, нинди рәт чыксын синнән, көне буе һаман шул кәгазьләрең белән утырасың, – дип бүлде аны эшеннән хатыны... – Мескенкәем минем, көннәр буе шулар белән маташасың, акчаң да юк, файдаң да...

– Тагын нәрсә инде анда? – дип, хатынына күтәрелеп карады ире.

– Үзең күрмисеңме әллә, раковина астыннан икенче көн бит инде су тама...

– Шулхәтле туйдырды мине бу нәрсәләр, – дия-дия, ире өстәл артыннан купты, – сантехникны үзең дә чакыра аласың бит инде...

– Сантехникны җүләр дә чакыра... Исеңдәдер, соңгы тапкыр чакыргач нәрсә булганын... Штукатур китерттек, страховщик та... Син бит учёный, эшлә үзең...

– Әй-йе-е, – дип кенә әйтергә мәҗбүр булды Тукранов, раковина астына кереп утырып.

Шуннан соң ул анда ярты сәгатьләп кайнашты, аннан чыгып, интернетта эзләнде, аннан соң хуҗалык товарлары кибетенә барып кайтты. Инде төн уртасында, билен тотып, башын калкытты.

– Булды, кил – кара... – диде ул хатынына.

– И җаныкаем, мин бит сиңа, синең булдырачагыңа ышанып яшим, – дип, хатыны иренең муенына асылынды. Ир шуның аркасында атна буе билен турайта алмыйча азапланды...

Атна үттеме-юкмы, хатыны кабат үтенеч белән килеп җитте:

– Кадерлем, син бит бөтен нәрсәне булдырасың, беләсең... – дип.

– Ну, тагын нәрсә кирәк сиңа? – Тукрановның тавышы теше сызлаган кебек килеп чыкты.

– Начальницамның эшендәге раковинасыннан да су тама икән, булышырга бер кешесе юк, булыша алмассыңмы, ә? – диде хатыны ялварулы, караш белән.

Ике көн буе Тукранов, хатынының начальницасын, фән докторы буларак шаккаттырып, сантехник вазыйфасы ролендә раковина астында кайнашты.

Аннан соң ул хатынының начальницасының дус кызларында сантехник җитешсезлекләрен төзәтеп йөрде. Аннары администрацияләрдәге, салым органнарында эшләүче, соцстрахтагы хезмәткәрләрнең, ниндидер кибет директорлары хатыннарының өйләрендәге һәм эшләрендәге ватык-ярык торба-сифон, фильтрларын төзәтеп арып-талып бетте. Хәтта бер журналист ханымныкын да. Анысы, рәхмәт йөзеннән, аның турында газетада реклама бастырды: "Тәҗрибәле, аек, зыялы сантехник фатирдагы барлык сантехника мәшәкатьләрен бик теләп, яратып башкарыр. Чакырсагыз, бик рәхмәтле булачак!" – дип язып чыкты.

Клиентлардан заказ өзелмәде. Өендә акча, кием-салым, кирәк-яракка хаҗәт бетте, хатыны гөл кебек чәчәк атты...

Барысы да яхшы якка үзгәрде, ләкин менә Тукранов, дуслары белән җыелышкач, үзенең фәнни темасын искә төшереп, авыр сулап куйгалады. Ник дисәң, кешеләр, аныкы кебек ачышлар ясап, Нобель премияләре алды, ә ул...

Әмма дуслары аның аркасын юкка яратып каккаламый:

– Бездә һәр эш мактаулы... Нобель лауреатлары буа буарлык, ә синең кебекләр, сантехниклар берничә генә... Күрәсең, синең язмышың шундый...



СЕКС-ШОП

Россиядә секс-шоп кибетләре күпләп ябыла башлады. Бер ел эчендә миллионнан артык кеше яшәгән шәһәрләрдә ике меңгә якын өлкәннәр өчен кибетләр юкка чыккан. Сәбәбе – интим әйберләрне яратучылар маркетплейс мәйданнарына агыла башлаганнар. Эшне сәүдә санкцияләре дә катлауландырган, шуңа күрә олылар продуктларына бәяләр даими күтәрелә. Ләкин, кризиска карамастан, Казандагы секс кибетләрне интернеттан эзләгәндә, дистә ярым адрес чыккан.

БЕР ТАМЧЫ ДА ЮК

Башкортстанның Кинзакеево авылында яшәүче халык исерекләр кибетен ябарга җыена – биш елга спиртлы эчемлекләр сатуны тыярга. Башта самогон ясаучыларны тыйганнар, аннары бердәнбер кибет хуҗасын авылга исерткеч эчемлекләр кайтартмаска ышандырганнар. “Коры бишьеллыкны” бу елның сентябреннән башларга планлаштырганнар. Ләкин, аяныч, башка “җавапсыз” авыллардан спиртлы эчемлекләр китерүне беркем дә тыя алмый.

КИЕМГӘ КАРАП

Якутиягә “Земский табиб” программасы кысаларында килгән гинекологка хатын-кызлар бертавыштан үзләренең ризасызлыкларын белдергәннәр. Социаль челтәрләрдә билгеләнүе турындагы хәбәр һәм аның фотосы пәйда булгач, хатын-кызлар аның шапшак сакалы һәм җиткән тырнакларына игътибар иткәннәр. Гинеколог маникюр ясатканчы һәм сакалын кырганчы приемга барудан баш тартканнар. Табибка хатын-кызларның таләпләрен тормышка ашырудан башка чара калмаган. Бонус буларак, табиб якут телен дә өйрәнә башлаган.

ЯРДӘМЧЕ КОНДЫЗЛАР

Чехиядәге Брды шәһәре хакимияте шатлыгына, акча кытлыгы мәсьәләсен хәл итәргә аларга… кондызлар ярдәмгә килгән. Җиде ел элек, табигый мохитне торгызу өчен, тыюлык зонасында буа төзү планлаштырылган булган. Әмма бюрократик киртәләр аркасында бу изге теләкләр тормышка аша алмаган. Көтмәгәндә хакимияткә ярдәмгә үткен тешле җәнлекләр килгән. Кондызлар, кирәк урыннарда елганы буып куеп, бюджетка 1,2 миллион доллар экономия ясаганнар.



Игорь КИЙКО

БЕР ФИКЕР

Рөстәм ЗАРИПОВ

Әдәбиятны очсызлый
Бүксәкагар “народныйлар” –
Беркем дә укымый торган,
Кәлҗемәләр калыплыйлар.


Үзләрен милләтче санап
Дулый мокыт, чиный надан,
Тәмам үтләрен кубарды
Гүзәл язган гүзәл роман.



Виктор ФЁДОРОВ











Евгений ОБУХОВ

ФАРМАЦЕВТ

Танышым Гарик Домановның үзенә генә хас юморы бар. Безнең компаниядә ул гел күз уңаенда. Торып баса да өстәл артыннан, рюмкасын югарыга күтәреп: "Әйдәгез, эчәбез!" – ди. Һәм тирән уйга калып: "Манчыйбыз... Әйләндерәбез... Каплыйбыз... Мәтәлчекләндерәбез чебурашканы... Кыйгаклатабыз бераз... Чөябез башкайны..." – дип тә өсти. Шуннан соң рюмкаларга өстәп йөри: "Ягез әле, кемгә тагын акны... Шуны бәдбәхетне... Толлар күз яшен... Тамак кырдыргычын... Це-два-аш-пять-оашечканы... Әчене... Кырык градусныйны... Агуны... Палёныйны... Этләтүчене..." Өстәл артында утыручылар тәгәрәп көләләр инде. Ә хатыны бик тәкәббер генә кыяфәт чыгарып утыра, башкаларга горур карашын ташлап, "менә, карагыз, минем ирем нинди!" дигәндәй.

Гарикның башка күрсәтерлек дәрәҗәсе булмагач, алар озак тормый аерылыштылар. Егерме еллап аның турында бер хәбәр дә булмады. Кинәт бер тапкыр проспектта ниндидер джип килеп туктады. Арткы ишегеннән Гарик чыгып килә, үзүзенә охшамаган: шәп костюмнан, ак күлмәктән, галстуктан:

– Сәлам, картлач, сине ерактан ук таныдым!.. Белдем... Сиздем... Фотога төшердем... Таптым... Тойдым...

– Сәлам, дускай! Сине хәзер әтиең исеме белән әйтергәдер инде?

– Юк, ла... Хәер, әйе – уңышлар бар. Хәзер фармацевтик компаниянең җитди бер секциясендә начальник мин.

– Вау! Син, нәрсә, әллә берәр җирдә укып чыктыңмы шул арада?

– Иманнән егылып төшмәдем лә мин укып йөрергә! Мине теләсә кайда болай да ике куллап эшкә алалар, талантлы мин. Хәзер мин яңалыклар кертү буенча генеральныйның урынбасары. Менә кара, менә безнең эшләнмәләр...

Гарик машинасыннан бөтен авыру кешегә дә таныш булган таблеткалар тутырылган пакет тартып чыгарды.

– Фирмагыз зурмы?

– Каян килеп зур булсын – бары тик бер конвейер, шулай гына булса да, бик зур уңыш китерә. Көне-төне ясый менә шушы, ничек әле... дербуталны. Без аның белән бөтенесен тәэмин иттек, аптекаларны тутырдык, инде алмый башладылар. Аннан мондый киңәш бирдем: "Әйдәгез, хәзер бу дербуталны дебартал дип атап, реклама компаниясе ясап алыйк? Һәм шулай эшләдек тә. Әйе, халык яңа дару белән кызыксына башлады. Шуннан соң фантазиям артканнан-арта, әллә нинди фикерләр килә һәм фирмабыз дербут, бутарала, фенитала, дербуфена, флоксетала, ксенитала, дербуйвейта, ксилокотила, веродерта, антиавыру чыгарырга тотынды...

Ул әле бик озак үзләре ясый торган продукция исемнәрен санады. Башымны чайкап утырдым да өйгә кайткач, аптечкабыздан әллә ничаклы җыелган "тылсымлы" даруларны чыгарып чүплеккә ыргыттым. Нигә аларны җыеп тотарга, аларның эчендәге таблеткалар бөтенесе бертөсле... берсен-берсе алыштыра торган... Однофигственно... тождественно... сходно... аналогично... лохоподобно... булганга.






Игорь КИЙКО

КҮЧМӘ МӘКТӘП

Яшел Үзән районының Осиново бистәсендә чираттагы иҗади кризис – балалар тагын музыка мәктәбеннән колак каккан. Инде ун ел чамасы яшь музыкантлар бер бинадан икенчесенә күчеп йөри. Бу юлы чираттагы сыену урынында спорт үзәге ясарга булганнар. Дөрес, гимназияләрнең берсендә алар өчен ике кабинет бүлеп биргәннәр, ләкин бары тик сольфеджио дәресләре өчен генә. Укытучылар белән инструментларда уйнарга өйрәнү өчен балаларга урын юк. Җирле хакимият инде күптәннән музыка мәктәбе өчен аерым бина төзергә вәгъдә итә, имеш, җире дә, проекты да бар икән. Әмма алда ни буласын әлегә беркем дә әйтә алмый.




Вячеслав ШИЛОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Валентин ДУБИНИН



Максим СМАГИН



Вячеслав ШИЛОВ

Юнус ЗУБАИРОВ

Керем

Телефоным шалтырады.

– Кем анда?

Номеры таныш түгел. Бер белмәгән кеше җитди тавыш белән минем фамилиямне, исемемне һәм әтиемнекен әйтә:

– Сезме бу?

– Мин.

– Ә мин – БТВ банкы хезмәткәре. Сезнең счётта шикле хәрәкәт барлыкка килде. Кемдер счётыгыздан акча алырга тели. Ахрысы, җыелган акчагыздан коры калуыгыз бар.

– БТВ банкыннанмы? – дип сорыйм.

– Нәкъ шуннан, – ди бу.

Ә мин: "Мошенниклар дип уйлыйм бит инде. Минем бу банкта да, башкаларында да бер тиен акча юк. Каян булсын инде? Пенсиядән пенсиягә көчкә җиткереп яшим бит. Акчаның канаты булмаса да, каядыр очып бетәләр..."

– Минем сезнең банкта алты гына миллионым ята, – дим. – Акча түгел инде бу? Вак-төяк. Менә Спёрбанктагы счётта миллиардка якын! Пеньков банкында тагын шуның кадәр. Акчамы инде ул – алты миллион?

– Бәлки, шулай да аларны куркынычсыз счётка күчерергә кирәктер?

– Әйе шул, әйбәт булыр иде... Менә шул турыда ныгытып сөйләшергә телефонымда акчам бетте...

– Шалтыратучыдан килгән сөйләшү бушка бит, – дип гаҗәпкә калды мошенник.

– Минем башка тариф бит, – дим. – Минем хәзер үземнең яхтада кызлар белән Канар утрауларына йөзеп барышым. Һәрберсенә – миллион вәгъдә иттем. Берни эшләп булмый, һәркайда кыйммәтчелек, инфляция. Үзегез уйлагыз. Бер буханка ипи илле тәңкә. Ә коммуналь хисап, транспорт... Көпә-көндез талыйлар!

Элемтәне өзәм. Биш минуттан телефоным тагын зеңгелдәргә тотынды. Балансны тикшерәм. Мең сумга тутырылган. "Яхшы, – дим. – Син ничек, мин дә шулай, артык түгел".

– Алё, – мин бу дип сөйләшә башлыйм.

Бу да:

– Бу тагын яңадан мин әле – банк хезмәткәре, – дип әңгәмәгә кушыла. – Нәрсә, куркынычсыз счётка күчерәбезме акчагызны?

– Әлбәттә! – дидем дә, моның номерын блокировать иттем.

Их, тагын берәр мошенник шалтыратса иде. Телефонымның балансын арттырыр идем. Ни дисәң дә, керем бит!



Игорь КИЙКО

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

ДӨРЕСЛЕК БЕЛӘН ЯШӘДЕК

Бик сагындыра үткән еллар. Элек тырышып эшләгән кешенең дәрәҗәсе дә булды, акчасы да.

Обком типографиясенә эшкә килгәч, бик яхшы сизелде андый хәлләр. Дус коллективта эшләдек, бер-беребезгә карата ихтирамлы булдык.

90 нчы еллар җитте. Безгә яңа начальник билгеләделәр. Душәмбе шәһәреннән. Беженка. Исемен әйтеп тормыйм. Рус кешесе булса да, ялагайлыкны, бүләкләрне бик тә ярата иде. Нишләтәсең инде, Урта Азиядә яшәгән бит, шунда өйрәнгәндер...

Көннәрнең берендә бу миңа бик җаваплы, авыр эш бирмәкче булды. Андый эшне иң югары квалификацияле кеше генә эшли. Юк, эшли белмим дип әйтүем түгел, беләм. Ләкин аның хезмәт хакы да артыграк түләнергә тиеш. Шуңа күрә мин каршы килдем.

– Акча ягы ничек булыр? Түлисезме? – димен.

– Нинди өстәмә кирәк сиңа? Эшлә! – ди бу кырыс кына.

– Юк инде, рәхмәт. Түләмәсәгез, үзегез эшләгез, – дидем.

– Алайса, гариза яз, – дип ачуланды.

– Гафу итегез, монда Урта Азия законнарын урнаштырмагыз. Сез Рәсәйдә, – дип җавап кайтардым.

Шуннан соң озак вакыт та үтмәде, коридордан барганда директорыбыз Дилбәр Талиповнаны очраттым. Туктале, дим, аңа мөрәҗәгать итеп карыйм. Исәнләшкәч, сүзне башларга булдым.

– Дилбәр Талиповна, – дим, – бер бик тә зур үтенечем бар иде Сезгә.

– Нәрсә булды? – ди.

Әйтми бит, үтенечләр белән, сорауларыгыз белән коридорда борчып йөрмәгез, приемга язылыгыз, дип. Туктап, минем белән сөйләшеп тора.

– Мөмкинчелек булса, эш хакымны арттырып булмас микән? Хәзерге заманалар авыр, үзегез беләсез, бәяләр артып тора.

– Ничек булмасын? Синең тырыш икәнеңне барыбыз да яхшы беләбез. Әйбәт эшче. Начальнигыңа ник әйтмисең, акчаны арттырыгыз дип?

Әйтеп булмый бит инде, сөйләшкән идем дә, шундый җавап кайтарды, дип.


– Сезне күргәч, башта сездән сорарга булдым. Мөмкинчелек юк микән дип.

– Мин каршы түгел. Начальнигыңа әйт, служебный язу язып, миңа кертсен. Кул куям.

Цехта начальникка шуны әйттем. Тешләрен кысып булса да, каршы килә алмады. Шулай хезмәт хакымны арттырдылар.

Әйе, ул вакытлар икенче иде шул. Әтиәнием, туганың кем дип сорап тормадылар. Тырышып эшләсәң сине күрделәр, хөрмәт иттеләр. Дөреслек белән яшәдек.

Эрнст ГЕЛЬМС, 1966 ел.



– Чолганышта калгач, үзебезне ничек тотарга өйрәнәбез...

Леонид ЕЛЬКОВИЧ, 1984 ел.



– Чираттагы тынычлык урнаштыру миссиясен үтәдек!



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Әгәр дә вакыт дигән нәрсә чыннан да дәвалый икән, ул чагында чираттагы соңгы авырулар район дәваханәсендәге табибка сау-сәламәт килеш кабул ителерләр иде.

• • •

Форбс исемлеге буенча яһүдләр дөньяда иң бай кешеләр булып санала. Бурычка сорасаң – иң ярлылар...

• • •

Блогерларның YouTubeдагы роликларын карап утырдым – күпме хезмәт хакы алалар икән, һәм аңладым: мин юк-бар нәрсә белән шөгыльләнәм түгелме соң? Миңа эшләргә кирәк, ә мин һаман роликлар карап утырам!

• • •

– Кызык, нигә сыраны тере дип эчәләр икән?
– Чөнки сәрхушләр аны иртән эчкәч, тереләләр!

• • •

– Минем әти, йөзгән вакытта, буйкаларны узып китә.
– Ә минеке урамны кызыл утка чыгып китә.
– Ә минем әти барысын да уздыра! Ул таныш булмаган телефон шалтырауларына да җавап бирә.

• • •

– Доктор, миндә газаплы авыру.
– Сезгә мәгънәсез яшәгән еллар тупланган.

• • •

Чын хезмәт кешесе бер стакан аракыдан соң, автомат рәвештә җыр укытучысына әверелә. Икенчесеннән соң философия укыта башларга мөмкин...

• • •

– Һәм менә Золушка принцка кияүгә чыга. Ул аның бүлмәсенә роза чәчәге таҗының яфракларын чәчте, ә төн уртасында алар носкиларга әйләнде...

• • •

– Кадерлем, ятакта мин нинди дә булса яңа алым кулланырга теләр идем.
– Әйдә соң, күрсәтәм, пододеяльникны ничек алыштырырга.

• • •

Пациент:
– Дөрес микән, наркоздан күпмедер еллар алынып, врачка бирелә икән?
Врач:
– Карале... 150 ел эшләп, бу турыда беренче тапкыр ишетәм!



Виктор БОГОРАД



Владимир СОЛДАТОВ



ИЗА ЧИГӘБЕЗ

Кадерле "Чаян". Дүрт ел элек Казанның "Савиново" паркы махсус саклана торган табигый зона статусы алды. Казансу елгасындагы Бердәнбер яшеллек утравы ул. Белгечләр аны экологиясе Кызыл китапка кертерлек флора-фаунасы булган урын дип әйтәләр. Әмма "махсус саклана торган статуслы җирне дә вакыты-вакыты белән карап торырга кирәк. Шушы кешеләр өчен яратылган урын чүплеккә күмелгән – монда хәтта контейнерлар да юк. Әле, җитмәсә, күптән түгел генә күгәрекле елгачыклар барлыкка килеп, алар Казансуга ага. Уйлавыбыз буенча, моңа төзелеш сәбәпчедер, чөнки бу табигый зона чигендә шундый эшләр башланды. Без инде төрле даирәләргә бу турыда хәбәрләр бирдек, ләкин сәбәпләр табып һәм аңлатмалар язудан башка җавап ала алмадык. Шуңа күрә елгалар ага тора, табигатебез, пычранып, чүпкә күмелеп, харап булудан иза чигә.

И. ГАБДРАХМАНОВ

КАЗАН

АНДА БАРМА, МОНДА ЯРАМЫЙ...

Хөрмәтле редакция! "Мой дом – моя крепость" дигән әйтем безгә – Терегулов урамының 4 нче йортында яшәүчеләргә кагылмый. Хәзер йортыбызның подъездыннан чыгу һәм керү тормыш куркынычы астында – фасадыбыздан кирпечләр коела. Ярый әле беребезнең дә башына төшмәде, ә менә берничә машинага эләкте. Бу зыян өчен кем түләр, аңлашылмый. Компания идарәсе һәрдаим ямау һәм вак-төяк ремонт эшләре белән шөгыльләнә, әмма кирпечләр безнең башны аулаудан туктамый. Безгә төзүчеләрнең начар төзү материаллар кулланганын әйтәләр, шулай булгач, бу йортка капиталь ремонт ясамый булмый бит инде. Кайчан ясыйлар әле аны, безгә кирпеч төшүдән качып йөрергә туры килә түгелме соң? Ә бит йорт яңа – аңа 13 кенә ел. Әлегә йортыбызны кызыл тасма белән уратып куйдылар, янәмәсе, машиналарны кирпеч төшүдән саклыйлар, ә безне ничек сакларга кирәклеге турында уйлаучы юк.

Терегулов урамының 4 нче йортында яшәүчеләр.

КАЗАН

Виктор БОГОРАД



• • •

Директор эшкә керүченең хезмәт кенәгәсен карый.

– Бергә эшли алуыбызга шикләнәм, – ди ул, башын чайкап.

– Нигә?

– Сез аз гына вакыт эчендә бик күп эш урынын алыштыргансыз.

– Тик мин аларның берсеннән дә үз теләгем белән китмәдем бит!



Сергей КОКАРЕВ



Рашат Мияссар улы Низамиев 1950 елның 1 нче мартында Татарстанның Саба районы, Олы Мишә авылында туа. Татар язучысы, шагыйрь. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге бүләк иясе, Шәйхи Маннур премиясе лауреаты, 16 китап авторы.

Укучыларыбыз игътибарына аның "Энҗе бөртекләрен эзләгәндә" (2002) дип исемләнгән язмасын һәм шигырьләрен тәкъдим итәбез.

РАШАТ НИЗАМИГА

Ул әле дә онытылмый,
Ул хәзер дә безнең арада.
Гөрләп шигырь укый иде,
Бер-ике көн килми тора да...

Куеныннан шигырь тарта,
Ә йөзендә Кояш балкышы!
Шагыйрьләрнең дә шагыйре –
Татарның ул яңа Такташы!

Җәлил дә ул бер мизгелдә,
Тач Сәйдәш тә, әнә, карагыз!
Аларга дип багышланган
Поэмасын укый, абзабыз!..

Аннан кучә юмор дөньясына –
Илдә-җирдә нинди кызык бар?!
Сәясәтне айкап чыкканнан соң,
Тетә барсын – кемнәр "сарыклар"...
Әйтеп куясың шунда болайрак:
"Бар иде дип, бездә, Рашатлар!"

МӘХӘББӘТ МӘРҖӘННӘРЕ

Малай чакта мәрҗән тезгән идем,
Тезгән идем яшел миләштән.
Үзем генә белгән мәхәббәтем
Әй, "яшел" булган соң ул яшьтә!

Егет чакта мәрҗән тезгән идем
Күк тутырып, кайнар йолдыздан.
Әле дә булса йолдыз сәламнәре
Килеп тора миңа ул кыздан.

Инде менә тагын мәрҗән тезәм,
Берәм-берәм тезәм сүзләрдән.
Җанда сөю – һаман шул ук икән!
Еллар гына бары үзгәргән.

Мәрҗән-мәрҗән тезәм елларымны:
Мин ни кылган, ниләр майтарган?
Күңел – һаман унҗидедә икән,
Еллар гына – бераз картайган...

НИШЛӘТТЕҢ?

Мәхәббәт фасыллары
Челтер-челтер сулар типкән чакта,
Элек язлар бүтәнчәрәк иде.
Гөрләвекләр тулып йолдыз ага –
Син нишләттең мине?

Шомырт ботагында тибрәп үстек,
Шомырт ашап теш камаша иде.
Шомырт күзләреңнән җан камаша –
Син нишләттең мине?

Урманнарда яфрак яуган чакта,
Элек көзләр бүтәнчәрәк иде.
Сары яфрак булып күктән тамам –
Син нишләттең мине?

Узып бозлы тәрәзәләр аша
Синең сулыш битләремә тиде.
Кар өстендә гөлләр чәчәк ата –
Син нишләттең мине?

ТОЛЫМНАР

Син яңадан кайттың күңелемә,
Күзләреңдә – шомырт төсе исән.
Сүзләреңдә – сөю, сагыну назы,
Толымыңнан иркәләргә дисәм...
Сискәнәм дә тынып калам кинәт,
Ах, бу җансыз кайчы, нишләгән!
Тәүге мәхәббәтем гөлен кискән –
Синең толымнарны кисмәгән!
Башын игән топольләргә карыйм,
Аларга да сагыну моңы тулган.
Мин бит сине элеккечә итеп
Иркәләргә телим толымыңнан!
Йөрәгемне кысып ала хәтер,
Газапланам,
янам,
кулым бармый...
Элеккечә сөя белү өчен
Кайтарыгыз миңа,
Кайтарыгыз ташкын толымнарны!

ТОРМЫШ ТРАМВАЕ

Барган шәпкә сикердем дә мендем,
Үз-үземә урын барладым.
Кеше икән – ул белергә тиеш
Кая таба үзенең барганын.
Әй җилдерә тормыш трамвае!
Көннәр, еллар кала сибелеп.
Яшьнәп яшәр өчен – бу тормышта
Гашыйк булу кирәк иң элек.
Тукталышлар күтеп тора безне
Туктап-туктап уйлап алырга.
Баш иясең яки дөреслеккә,
Яки инде дөнья малына.
Биеклектә калыр өчен кеше
Күтәрелеп менә түбәннән.
Бу сәфәрнең хакы әллә кайчан
Әнкәң каны белән түләнгән.
Зурлыгына, акылына карап
Или язмыш адәм баласын.
Коры кибәк булсаң, эшләр харап:
Җил уңайга төшеп каласың.
Семафорда утлар җемелдәшә...
Таңнан алып таңга кадәри
Вакыт рельслары буйлап әнә
Тормыш трамвае тәгәри.
Күкрәк белән ерып бара КЕШЕ,
Этеп бара еллар киртәсен.
Сизми ләкин... соңгы тукталышка
Кайчан, ничек килеп җитәсен.

ЯЛГЫЗЛЫК

Иң якты бер йолдыз идең
Күгемдә күңелемнең.
Метеор күк атылдың да
Яктылык чәчеп сүндең.
Зәңгәр күлгә төштең микән
Юарга сагышларың?
Ишетәм ялгыз аккошның
Моңайган тавышларын.
Өй түремдә каеннарым
Сары сагыш бөркәнде.
Диңгезләрдән эзлим сине,
Җил каера җилкәнне.

ЭНҖЕ БӨРТЕКЛӘРЕН ЭЗЛӘГӘНДӘ

Очрашулар вакытында безгә еш кына бер үк сорауны ишетергә туры килә: шигырьләр ничек һәм ни өчен языла?

Һич кенә дә аптыраганнан, эч пошканнан түгел, шигырьләр фәкать күңел сызланудан языла! Гамь уйлата, әйтер сүзең ашыктырып-сагынып көтеп тора сине. Иҗат эше, асылда, дөньяны һәм үз-үзеңне танып белүнең хикмәтле бер төре.

Кеше күңеле – дәрья, диләр. Чыннан да, анда нинди генә тетрәнүләр, кичерешләр, мәхәббәт фасыллары, хакыйкатьне аңларга тырышу мизгелләре булмаска мөмкин.

Кыскасы, һәммәбезнең дөньяны, тормышны үзенчә танып беләсе, хакыйкатьнең бер генә бөртек энҗесен булса да замандашларга җиткерәсе килә. Шигырь яисә чәчмә әсәрләр язу, иҗатка омтылыш – менә шуның бер чагылышы булса кирәк.

Үзебез яшәгән җәмгыятькә игелек эшләргә уйласак, туган телебезне, милли мәдәниятне һәм татарлыгыбызны саклап калырга теләсәк, бу эшкә олысыннан алып кечесенә кадәр үз өлешен кертергә бурычлы. Берәүләр – дәүләт урамын, икенчеләр гавам урамын чиста тотканда гына, без алга таба бара алачакбыз. Монда инде зур әдәп, әхлак, батырлык һәм тормыш тәҗрибәсе сорала. Ходай кушып, безнең моңа көчебез җитсә иде.

Төрле кешедә төрле холык бит. Трибуналарда, митингларда әйтеп булмаганны кайчак шигырьдә шәбрәк һәм үтемлерәк итеп әйтеп була. Шигырь ул – үз-үзең белән сөйләшү генә түгел, дусларың яки дус булмаганнар белән дә бәхәсләшү, уй-хисләрнең кайнар тупланышы. Шигырь ул – тормыш өчен, яшәү өчен, дөнья матурлыгы өчен көрәш...



Дамир БӘДРИЕВ

ГӨЛҖАМАЛГА ЧАК ӨЙЛӘНМӘДЕМ

Әни: "Өйлән!" – дип, сәгать күкесе кебек кабатлап кына тора. Бик өйләнәсе дә соң, авылда кызлар юк бит. Шәһәрләргә китеп беттеләр. Колхозларны таркатып харап иттеләр авылны. Ялгыз әби-чәбиләр генә калды утырып.

Өйләнергә каршы түгел инде мин үзе. Әйтәм бит, авылда кызлар юк. Мәктәптә бер-ике кыз буйга җитеп килә анысы. Укуларын тәмамлагач, аларның берәрсенә өйләнсәң, ул сине барыбер җитәкләп шәһәргә алып китәчәк. Картаймыш көннәрендә әти белән әнине ташлап китү гөнаһ булыр.

Казанга барып, кызлар күзләп кайтырга ниятләдем. Берсе: "Авылга мәңге кайтмыйм, анда эш урыны юк", – ди. Икенчесе: "Ашарга пешерергә, кер юарга яратмыйм", – ди. Ризык әзерләмәгәч, чисталыкны теләмәгәч, нинди хатын була ди инде ул?! Трамвайда бер кызга күзем төште: зифадан-зифа гәүдәле. Ул аяклары, ул гәүдәләре! Чуп-чуп үбеп кенә ятарсың. Шул кыз миңа борылып карады, сискәнүдән трамвай идәненә егыла яздым. Битенә пластик операция ясаткан, балта һәм пычкы белән генә эшләгәннәр, ахрысы. Каберennән кубарылган Тутанхамон мумиясе дә болай ук куркыныч түгелдер. Моның "үрдәк" иреннәре крокодил авызы кадәрле. Томшык кадәрле түгел, томшык күгәрчен белән чыпчыкта гына була ул. Кайбер акылсыз кызлар Африкадагы кабилә кешеләре шикелле аскы иреннәрен чәй тәлинкәсе зурлыгында тарттыра башласа нишләрсең, Ходаем.

Казанда насыйп ярымны очрата алмыйча, кире авылга кайтып киттем. Бер көндә генә каян табасың инде аны? Аптырагач, кәләшне кәрәзле телефонда социаль челтәрләрдән эзли башладым. Авылда телефоны да юньләп тотмый, каһәр суккыры нәрсә. Телевизор янында, тәрәзә каршында яки өйнең берәр почмагында "элемтә дулкыны" тотып азапланасың. Әни: "Тегендә-монда йөренеп, чебен куалыйсыңмы соң син?" – ди. "Телефоннан сиңа килен эзлим. Чебене чурт с ним", – дим. Килен сүзен ишеткәч, әни: "Амин!" – дип, догалар кылып куя, бәгырькәем.

Социаль челтәрдә күңелемә бик тә хуш адреска тап булдым. Исеме дә шундый матур. Гөлҗамал. "Татар милли ашларын, чисталыкны яратам. Мактанчыкларны, ялганчыларны һәм ялагайларны җенем сөйми. Авылның киләчәге өчен борчылам", дип язган. Нәкъ минем уйларымны тезеп салган, рәхмәт төшкере.

"Фоторәсемеңне дә куй әле, бик күрәсем килә үзеңне", – дип, СМС җибәрдем. Берзаман Гөлҗамалның социаль челтәрдәге битендә сакаллы абзый пәйда булды. Ялгыш әтисенең яки абыйсының фотосын урнаштыргандыр дип уйлаган идем. Юк икән, Гөлҗамал ир кеше булып чыкты. Әти белән әни минем төн уртасына кадәр мужик кешегә сәламнәр җибәреп утыруымны белсә, икесен тиң инфаркт сугар иде, билләһи. Бу адреска телефонымны, гомумән дә, томаладым.

Бәхетеңне керпе селкесә, булмый инде ул, дип, төшенкелеккә бирелдем. Ходайның рәхмәте, авылыбызга үзбәк гаиләсе күченеп кайтты. Олы кызлары Гөлҗамиләгә күзем төште, өйләнештек. Көн саен пылау пешерә үзбәк хатыным. Әни сөенеченнән Ашхабад кояшы кебек балкып йөри. Эт корсагына сары май килешми дигәндәй, минем бәдрәф юлыннан кайтып кергән юк. Маемлатты чистый. Ничава – түзәрбез! Бетә ул. Аның каравы, хатын шәп!

Рөстәм ЗАРИПОВ

ЯЛГЫЗ КАЛСАҢ...

Ялгыз калсаң, очрашасың үзең белән,
Үз-үзең зарын тыңлыйсың түзем белән.
Ялгышларын искәртәсең чытып кашны,
Һәм ул таный хаталарын, иеп башны...

Орышасың бахыркайны, чырай сытып,
"Их син ахмак, сантый, җүләр, тинтәк, мокыт..."
Гүяки уклар атасың, җәя белән,
Ул килешә, син чыгарган бәя белән...

Йөзеңә чәпәсә әгәр берәр бәлеш,
Үз-үзеңә әйткәннәрдән тик бер өлеш,
"Дөрес түгел, дошман сүзе, яла", дисең,
"Үзеңне бел, үз бүрегең яна", дисең...

Гаҗизләнтән, егыласың барып дуска,
Чишеләсең, йөрәгеңне кысып учка.
Ә ул әйтә, "артык тирән уйлама", ди,
"Барыбыз да синең сыман кылана", ди.

Кешегә бит ялгыз калу да бик кирәк,
Гел һәм озакка түгел, ә сирәк-мирәк...
Юкса онытуың мөмкин үз-үзеңне
Һәм әйтә алмый башлавың үз сүзеңне...

...Ялгыз калсаң, үзең белән кавышасың...
Дөреслеккә түзү кыен, карышасың.
Бата башласаң, саламга ябышасың...
Әңгәмә озакка китсә, авышасың...





ЧАЯН
САТИРА һӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 3 (1952) март 2025

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Татарстан Республикасы,
Казан, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылса алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан,
Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.03.2025 ел.
Тираж – 1476 Заказ М-0293
Редакциянең адресы: 420066,
Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

"БЕР ТАУДА ... ЧИШМӘ"

МИНСКИЙ ...

"ҺАВАЛАРДА ... ИКЕ АККОШ"

"... ОЧА ИДЕЛДӘ"

...-СУ

НОТА

ШАХМАТ ФИГУРАСЫ

ЯЗ АЕ (-1)

ПРИМАТ

КНИТУ-... (аббр.)

СИХЕР

ФУТБОЛДА МАТЧНЫҢ ӨЛЕШЕ

ХУШ ...

"ИДЕЛЕМ, ГЕЛ СИҢА ..."

ЦИТРУС

"... ТРАГЕДИЯСЕ"

НОТА

"... ЧӘЧӘК АТА ИЛЕМ"

ОЕШТЫРЫЛГАН СӘЯХӘТ

ЧЫРШЫ БОТАГЫ

... ЗӘЛКАРНӘЙ

"ИРЕННӘРЕ ... ГЫНА"

"ТӨЛКЕ УЙНЫЙ ТОРГАН ...ЛАР БАР"

... МӨХӘММӘТҖАН

АРТИСТ РИНАТ ...

НӘСЕЛ-...

КАЛЫН

БАЛА АТ

"...-ЕГЕТЛӘР"

ГАЛИМ ... НАСЫЙРИ

ЕВРОПАДАГЫ БАШКАЛА

БӘЙРӘМ ... — КАРА-КАРШЫ

АЗИЯДӘГЕ ИЛ

365 КӨН

БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЕ

"ЕРАК ХӘЗЕР ...ЛАР"

КӘГАЗЬ-...(-1)

АТУ КОРАЛЫ (аббр.)

АРТИСТКА ... ИЛЬСКАЯ

ТАРТТЫРЫЛГАН ЯРМА

БЕНЗИН МАРКАСЫ (аббр.)

АЛИШ "... ЧӘЧӘКЛӘР"

... ӘБУБӘКЕРЕВ

УҢАЙ ЭЛЕКТРОД

... ГЫЙСМЕТДИНОВ

ҺӨҖҮМ АВАЗЫ

ЖЫРЧЫ ӘЛФИЯ ...

ЧАЯН

ТАБЫШМАК БИР, Л АЛЫШМАК

1. Нинди хатыннар үзләренең фигураларын иплəп йөртә?

2. Тәбедән бушлай сыр кем ала?

3. Сәгать алтыдан соң ашамаска нинди ысул яхшы?

4. Җүләрне алдарга бик җайлы дигән нәрсә дөресме?

5. Күгәрченнәр сиңа игътибар юнәлтсеннәр өчен нишләргә кирәк?

6. "Мәшәкатьсез бакча" нәрсәне аңлата?

7. Нинди очракта хатын-кыз ирен игътибар белән тыңлый?

ҖАВАПЛАР

1. Шахматчылар. 2. Икенче тычкан. 3. Алтыга хәтле ашап куеп. 4. Әйе. Ләкин: "Син бит бик акыллы кеше..." дип кабат-кабат әйткәләп торырга онытмагыз. 5. Һәйкәл булырлык абруйга ирешергә. 6. Акчаңны алып базарга бару. 7. Ире кем беләндер телефоннан сөйләшкәндә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 2 нче санында басылган чаянвордның тикшеру сүзе – **«ХАФИЗӘЛӘМ, ИРКӘМ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. ТУКМАНОВ (Казан),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Апастан **Зәйнәп ЯРУЛЛИНА!**


Сергей СОКОЛОВ






Сергей Соколов беренче карикатурасын 12 яшендә бастырган. Һәм шуннан соң инде киткән: журнал һәм газеталарда рәсемнәр, китаплар бизәү, халыкара конкурсларда катнашу, җиңүләр, бүләкләр, призлар... Юмористик эшчәнлек Сергейга җитди эш белән шөгыльләнергә һич кенә дә комачауламый – ул Чиләбе өлкәсенең Снежинск шәһәрендә конструкторлар төркеме җитәкчесе, өстәвенә, профсоюз активисты да. Ә ясаган карикатуралар күләменә килгәндә, аларның саны бүгенге көнгә ике меңнән артып киткән. Ә бу инде Сергей Соколов "Чаян" вернисажы өчен өлгергән диган сүз!







4612750670080